РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
МЭР ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МЭРЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**3 декабрь, 2024 ел** **№ 13**

«Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында» Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

Кукмара шәһәре Советының 2023 елның 25 декабрендәге 28 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Кукмара шәһәре Советының 2020 елның 17 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып карар бирәм:

1. 2024 елның 18 декабрендә 17 сәгать 00 минутта Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 15 йорт адресында урнашкан Кукмара шәһәре Башкарма комитеты бинасында (1 нче каттагы 107 нче кабинет) түбәндәге мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар уздырырга:

- Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш.т.п., Степан Разин ур., 67а й. адресында урнашкан 16:23:260115:249 кадастр номерлы, мәйданы 444 кв. м булган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Кукмара шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре транспорт инфраструктурасы зонасында (Т) «Автомобиль юу урыннары» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлегенең капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү:

- җир кишәрлеге чикләреннән минималь чигенешләрне киметү өлешендә 1 нче ноктадан 2 нче ноктага кадәр – 0,40 м га кадәр, 3 нче ноктадан 4 нче ноктага кадәр – 0,00 м га кадәр, 4 нче ноктадан 1 нче ноктага кадәр – 1,00 м га кадәр (кушымта).

2. Гавами тыңлаулар уздыру башлануы турында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында https://kukmor.tatarstan.ru һәм Кукмара шәһәренең гавами тыңлауларда катнашучыларның күрсәтелгән мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итә торган мәгълүмат стендларында түбәндәгеләрне урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә:

1) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар, гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышының яисә җыелышларының датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат;

2) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм шушы проектка карата мәгълүмати материаллар исемлеге;

3) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат;

3) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенең яисә экспозицияләренең урыны, ачылу датасы турында, мондый проект экспозициясен яки экспозицияләрен үткәрү вакыты турында, күрсәтелгән экспозицияне яки экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

5) гавами тыңлауларда катнашучыларның гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм рәвеше турында мәгълүмат;

- «Капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында» боерык проектын һәм аңа мәгълүмати материалларны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында https://kukmor.tatarstan.ruурнаштырырга;

- 2024 елның 03 декабреннән 2024 елның 18 декабренә кадәр Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15 йорт адресында урнашкан Кукмара шәһәре Башкарма комитеты бинасында гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозицияләрен ачарга һәм уздырырга. Экспозицияне эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату оештырылырга тиеш;

- гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

- гавами тыңлауларга әзерлекне, гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын билгеләнгән вакытта уздыруны тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләүне һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар йомгаклары буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында https://kukmor.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кукмара шәһәре Башкарма комитеты каршындагы җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә йөкләргә.

**Кукмара шәһәре мэры** **С.Д. Димитриев**